Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл жирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл торак пунктларында гражданнар жыены нәтиҗәләре турында

30 ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге № XIVномерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Башлыгының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авылы торак пунктларында гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе турында гражданнар җыенын билгеләү " 2021 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, “2021 елның 30 ноябрендәге 6 номерлы, авыл җирлеге буенча Халык җыенының йомгаклау беркетмәсен игътибарга алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәнгәр Күл авыл җирлекләрендә гражданнар җыены КАРАРы:

1. 2022 елда сайлау хокукына ия булган, Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлегендә Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче группа инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз яшәүче пенсионерлардан тыш, (гомуми саны 30 проценттан артмаган очракта) һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Күгәрчен авылында Гагарин, Зәңгәр-Күл авылында Куйбышев урамнарына вак таш сатып алу һәм юлларны ремонтлау(вак таш сатып алу, вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү, вак таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- мәктәпкәчә төркем балалары өчен мәйданчык төзекләндерү(инвентарь сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Күгәрчен авылында су торбаларын ремонтлау(эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү килешү буенча) ;
- Күгәрчен авыл җирлеге һәм Зәңгәр Күл авылы торак пунктларындагы юлларның йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү килешү буенча) ;
- су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү килешү буенча).

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Кәгәрчен авыл җирлегенең Кәгәрчен авылы, Совет урамы, 62А йорты адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы А.Т.Сафин.